# Бүген—шимбә өмәсе. Барыгыз да хезмәт бәйрәменә!

СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №46 (7219) | 20 апрель, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

## «Чәчү-91» пресс-үзәге хәбәр итә

**Язгы кыр эшләре акрын гына колач ала. 19 апрельгә районда 1504 тонна орлык инкрустацияләнде, 3794 гектарда туңга сөрелгән җирләр тырмаланды. Уҗым культураларын тырмалауга «Заря», «Ленинский путь», «Татарстан», «Алга», «Комбайн», XXI партсъезд исемендәге колхозлар, «Мамык» совхозы да уңышлы гына керешеп киттеләр. Бу эш 812 гектарда башкарылды. Күпьеллык үләннәрне тукландыру һәм тырмалау да дәвам итә. Аның беренчесе 2730, икенчесе 2915 гектарда үтәлде. XXI партсъезд исемендәге, «Алга», «1 Май», Таң», «Заветы Ильича» колхозлары, «Төрнәс» совхозы бу эшне аеруча әйбәт алып баралар.**

### ӨМӘДӘ

Нефть базасы коллективыннан өмәгә 6 дистәләп кеше катнаша. Аларның 40 процентка якыны көндәлек эш урыннарында эшли: һәртөрле транспортны, шул исәптән тимер юл составларын да ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итәләр. Калган эшче һәм хезмәткәрләр база хуҗалыгын, резервуарлар паркын, үзебезгә беркетелгән территорияне төзекләндерү һәм яшелләндерүдә эшлиләр.

**О. МИХЕЙКИН.**

# ӨМЕТЛЕ ЯЗ

Быелгы яз игенчене йөгәнләгән ат сыман тота. Һай, корыч айгырларга утырасы иде дә яшел хәтфә булып күтәрелгән уҗым басуларын тукландырурга, я актарылып ташланган туңга сөрелгән мәйданнарны тырмаларга керешәсе иде дә бит—юк, юк, һаман салкынлык кулдан тота, һаман җир җылынмый, туң бетми. Иртән куерган болытларга карап, XXI партсъезд исемендәге колхоз механизаторлары да бик өметтә торганнар иде: «Яварявар»,—диештеләр. Юк, әлләни булмады. Инде менә Хөҗҗәт Мирзаханов җитәкчелегендә егетләр 250 гектарлы арыш җирен тукландырырга керешергә булдылар. Бирегә азотлы ашлама кертәчәкләр егетләр, артыннан ук тырмалау да үткәрелә. Участокларны карап кына, сайлап кына эшләргә туры киләчәк, әлбәттә. Әнә 3 агрегатны янәшәдәге туңга сөрелгән мәйданнарны тырмалауга төшергән иделәр дә—иртәрәк булып чыкты, эш тукталды. Механизаторларның да кәефе кырылып китте: бер җыенгач эшлисе иде дә бит!

Гомумән, XXI партсъезд исемендәге колхоз игенчеләре теләк, омтылыш белән көттеләр язгы чәчүне быел. Районда беренчеләрдән булып аңа керештеләр дә. Хөҗҗәт Мирзаханов моңа кадәр туңга сөрелгән җирләрне тырмалауда булды. Өченче ел язын басуда каршылый инде ул, һәр эшнең җаен, тәртибен белеп, теләп эшли. Урып-җыю вакытында да комбайнга утыра. Бүген бергә эшләүче иптәше Җәмил Гайнуллин да шулай. Хәер, игенчегә эш бетәме җәен? Әнә хезмәттәше Фәрит Вәлиевны АВМ, аннан механикалаштырылган ындыр табагында эш көтә, Галим Әхмәтҗанов та буш булмаячак.

—Егетләр эшли торганнардан,—ди колхозның баш агрономы И. Рәхмәтуллин, аларны мактап. Аның хәзер шулай ук бик мәшәкатьле көннәре. Бүген чөгендер орлыгын кайтарып бетерәчәкләр. Әнә бер участокта уҗым бодае саргаерга охшап утыра—тукландырырга кирәк. Шул ук вакытта механизаторлар эшен дә күздән җибәрергә ярамый. Шуңа бөтен нәрсәдән хәбәрдар ул. Әнә күпьеллык үләннәрне тукландыруда эшләгән Зиннәт Вафин агрегатын мактап алды. Шунда ук хатын-кызларның орлык инкрустацияләү буенча да әйбәт эшләүләрен әйтеп узды. Әнә 4 нче 350 гектарлы кырда туңга сөрелгән җирләрне тырмалауда эшләүче егетләр янында да берничә кат булып килде. Рәис Борһанов, Нәҗип Нуретдинов, Илшат Нигъмәтуллин, Ришат Сәйфуллин бик карап кына, саклык белән генә эшне туктатмаска тырышалар әле. Инде бик кыенга килсә—әлеге дә баягы өлгергән җирләрне сайлап эшләргә туры киләчәк.

Елга зур өмет баглыйлар игенчеләр. Техника тулысынча итеп сафка бастырылган, кадрлар җитәрлек, оештыру мәсьәләләре уйланылган. Әнә, сөбханалла, арыш уҗымнары нинди тигез күтәрелгән—яңадан чәчү белән мәшәкатьләнәсе булмас кебек. Үстерәсе иде кыр тутырып иген, җыясы иде муллыктан келәтләр сыгылырлык икмәк—тансыклады бит игенче муллыгын да мактавын да, уңышын да.

Агрегат туктап торганда, шул хакта гәпләшеп алдылар игенчеләр. Шулай шул, муллык та, уңыш та бигрәк тансык нәрсәгә әйләнеп бара тормышыбызда. Кем белә, бәлки быелгы орлыклар аның беренче шытымнарын бирерләр? Игенчене шул өмет яшәтә, эшкә туплый, шул хис аңа ышаныч тулы дәрт һәм дәрман өсти.

**С. НУРУЛЛИНА,**
XXI партсъезд исемендәге колхоз.

## 22 апрель—В. И. Ленинның тууына 121 ел

**В. И. ЛЕНИН.**
ТАСС фотохроникасы.

## Секретарь сайланды

17 апрельдә Норлат шикәр заводында партия җыелышы булып үтте. Җыелышның көн тәртибендә оештыру мәсьәләсе иде.

Башлангыч партия оешмасы секретаре П. П. Хормушковның ялга китүе сәбәпле эштән азат итү турындагы гаризасы канәгатьләндерелде. Башлангыч партия оешмасы секретаре итеп Л. Н. Горшенина сайланды.

Җыелышта партия райкомының оештыру-партия эше һәм башлангыч партия оешмаларының эшчәнлеген яңарту буенча КПСС райкомы комиссиясе рәисе урынбасары Ф. Ш. Галимов катнашты.

## Л. Н. ГОРШЕНИНА

Людмила Николаевна Горшенина 1961 елда Норлат шәһәрендә туган. Югары белемле инженер-технолог. 1984 елның апреленнән декабренә кадәр Хабаровск крае Эльбан поселогында «Восход» производство берләшмәсендә мастер булып эшли. 1985 елның январеннан Норлат шикәр заводында агроном-инспектор вазифасын башкара. 1985 елның сентябреннән 1990 елның сентябренә кадәр шул ук заводта инженер-химик булып эшли. Шул вакыттан алып бүгенгәчә шикәр заводында сыйфат буенча инженер-технолог вазифасын башкара.

## *Ленин исеме белән*

Ленинның тууына 121 ел тулу алдыннан 1 нче мәктәпнең рус теле һәм әдәбияты укытучысы Л.И. Сидоренко инициативасы белән 11 классның әдәбият дәресенә СССР журналистлар Союзы члены Ф. А. Савгачев чакырылган иде. Ул үзенең язучы М. Шагинян белән очрашуы турында сөйләде. Чөнки язучының иҗаты В. И. Ленин исеме белән нык бәйле. Ул аның турында күп язган. Балалар әлеге очрашуны магнитофон тасмасыннан тыңладылар. Дәрес җанлы һәм кызыклы узды.

**Л. КУКОЛЕВА,**
мәктәпнең укыту бүлеге мөдире.

# Соңгы көндә

«Восход» колхозы игенчеләре белән очрашу 17 апрельдә, ягъни хуҗалыкның техника паркындагы соңгы көне үтте. Икенче көнне авыл халкы катнашында җыен үткәрү билгеләнгән иде. Соңгысы кырга чыгу дигән сүз инде.

Мастерской тирәсендә барлык төр тагылма техника агрегатлаштырып тезеп куелган. Аларга көйләү үткәрелгән, күрше колхоздан килгән ярышташлары тикшерү уздырган. Бу сынауны уңышлы узган хуҗалык механизаторлары: хәзерлекләре яхшы дип табылган.

Хәер, болары басудагы төп көч—тракторларга да кагыла. Алар да чәчү сәрына дип сыйфатлы хәзерләнгән.

Мастерскойда берничә трактор кырга чыгу алдыннан тикшерү уза. Алар янында механизаторлар мәш килә.

—Алар да бүген тулы хәзерлек сызыгына куелып мастерскойдан чыгачак,—ди колхоз партия оешмасы секретаре Николай Абрамов.

Мастерскойга әледән-әле механизаторлар керә, чыга тора. Аларның йомышы токарьга, соңгы заказлары белән керәләр. Алда торган эшләр турында гәп куертабыз. Һәркайсының күңеле күтәренке, басуга чыккач сынатмаска исәпләре. Евгений Демьянов, Петр Лаврентьев һәм башка механизаторлар да шул фикерне гәүдәләндерәләр.

Николай Нагорный шикәр чөгендер звеносы составында эшләячәк. Бу звено членнары да үз агрегатлары янында, кырга чыкканчы техникаларын әнә күзеннән кичерәләр.

Паркның башка урыннарында да шул ук мәшәкатьләр белән мәш килде игенчеләр. Профсоюз комитеты рәисе Владимир Оспенников та шуңа хас уй-теләкләр кичерде: алдагы көндә узасы җыенга хәзерлек иде күңелендә.

—Безнең бурыч, игенчегә нормаль хезмәт өчен барлык шартларны да тудыру,—диде ул бу уңайдан. —Һәм без төп игътибарны шуңа юнәлдерәбез дә. Ул туклану, ярыш оештыру мәсьәләләрен күздә тотып әйтә моны. Экономист Алексей Васильевич Алексеев шул ук җыенга кырда эшләүчеләр өчен түләү нормативларын яңабаштан әзерләгән: һәр төр эш өчен хезмәт хакы арткан.

Восходлылар әнә шулай яз мәшәкатьләре белән яшәделәр, күңелләре белән басуда иделәр инде ул көнне.

**Р. АЙЗАТУЛЛИН.**

## Укучылар игътибарына!

**Язгы чәчү эшләре башлану уңае белән «Дуслык» газетасы редакциясе укучыларга кыр эшләре турындагы хәбәрләрне оператив җиткереп тору максатыннан чыгып үзенең эшен вакытлыча үзгәртте һәм газета дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе көннәрендә ике битле, шимбәдә дүрт битле итеп чыгарыла башлаячак.**

*БӘХӘС КЛУБЫ*

# Киләчәгебез бармы?

Район газетабыз битләрендә рухыбызны күтәрә торган мәкаләләр күренә башлады. Шуларның берсе газетаның быелгы 39 нчы санында басылган К. Сәлимова мәкаләсе. Мин язарга теләгәннәрне ул алданрак язып өлгергән. Рәхмәт аңа.

Чынлап та, татар мәмләкәтендә яшәсәк тә туган телебез дәүләт теле түгел. Бу нәрсә кәгазьдә генә калып килә.

Имеш, балаң белән син өйдә генә туган телеңдә сөйләшә аласың. Яслендә, балалар бакчасында һәм мәктәптә балаларыбыз гел русча гына сөйләшергә мәҗбүр. Нәтиҗәдә балалар телдән һәм туган милләтеннән читләшәләр. Үз диненнән, үз теленнән ваз кичкән җан иләреннән киләчәктә нәрсә көтәргә соң? Бу җәһәттән район халык мәгарифе бүлегенә шундый соравым бар: 1991 елның сентябреннән районыбызның һәм Норлатның ясле-бакчаларында татар группалары оештырыламы? Мәктәпләрдә татар класслары ачылачакмы? Гомумән, сез бу мәсьәләләр хакында ни уйлыйсыз, педагог иптәшләр?

Ә бит балаларны без начарлыкка бик яхшы өйрәтәбез. Мәсәлән, Кормыш янындагы микрорайонда кабель аша видеофильмнарны хәзер күп кенә квартираларда карыйлар. Экрандагы җанны өшетерлек үтерү һәм көчләүләр, шәрә хатыннар һәм ирләргә карата җитәкче иптәшләр, ата-аналар нигә шулай ваемсыз, битараф калалар?

Мондый «тәрбия үзәкләре» Норлатның башка урыннарында да гөрләп эшләп тора. Әйтик, шәһәр кинотеатрында «Кечкенә Вера», «Арлекино» һәм башка фильмнарны күрсәтүнең максаты нәрсә? Оешманың акча планын тутырабыз дип киләчәк буынның бәхетенә кул суземыйк. Әлеге «тәрбия»нең нәрсәгә илтүе хакында «Дуслык» газетасының 38 нче санында чыккан «Мин Камыш бухтасыннан аваз салам» дигән мәкаләдә бик тәфсилләп язылган. Әгәр барыбыз да битараф булып йөрсәк, мондый вәхшилекләр безгә дә килмәс дип кем әйтә ала соң?!

Туган телебезнең абруе мәсьәләсе мине икенче яклап та борчый. Татарлар күпчелекне тәшкил иткән җирдә җыелышлар, җыеннар һәм бәйрәмнәр нигә туган телебездә үткәрелми соң? Барлык союздаш республикаларда да бу шулай оештырыла бит. Вакытлы матбугат һәм радио-телевидение аша күргәнең чыгып сөйли дип кенә уйламагыз. Мин өч ел Үзбәкстанда яшәдем һәм төзелештә эшләдем. Анда 100 дән артык милләт кешесе бик тату яши иде. Мин анда 1 ел эчендә үзбәкчә сөйләшергә өйрәндем. Шунда яшәгәндә бер хакыйкатькә инандым: җирле халыкның телен белү ул әлеге милләтне санлау һәм ихтирам итү икән. Үзбәкстанда яшәүче, башка милләт кешеләре дә үзбәкчә яхшы сөйләшәләр. Шуның өчен дә аларны үзбәкләр дә ихтирам итә, якын күрәләр. Ә нигә бездә үзара шундый саклашу юк икән? Минемчә, чын интернациональ рухта тәрбияләнгән совет кешесе нинди милләттән булуына карамастан тигезлек дигән төшенчәне оныттырга тиеш түгел. Бу тигезлек милләткә дә, телгә дә, дингә дә, сәясәткә һәм икъдисатка да кагылырга тиеш.

Ә бездә? Киекле, Кизләү кебек борынгы татар авылларында да урам исемнәре русча. Шул ук Үзбәкстанның заманча төзелгән яңа шәһәрләрендәге урамнар беләсезме, ничек аталганнар: Алмалык шәһәре, Кыр гөле, Тынычлык, Дуслык, Хезмәт, Яшьләр урамнары яңгырашлары белән күңелне иркәләп торалар. Менә алар ничек тәрбияли милли рухны! Ә бит мәдрәсәләрдә белем алган татар галимнәре һәм мөгаллимнәре заманында бөтен Урта Азияне аң-белемгә өйрәткән. Аларның алтын буыны әлеге халыклар арасында мәгърифәтчеләр, әйдәп баручылар буларак ихтирам казанганнар. Ә бүгенге көндә шул алдынгы халыкның бетүгә табан йөз тотуын ничек аңларга?

Милли бәйрәмебез—Сабан туе турында да әйтәсем килә. Соңгы елларда Сабан туйлары рус бәйрәменә охшап кала. Мәйдандагы тавыш көчәйткеч җайланмалардан килгән авазлар бәйрәмнең тыйнаклыгын бетерә. Чыгышларны, белдерүләрне дә башта татарча, аннан русча әйтергә вакыт җитте, ләбаса. Безнең әби-бабайлар: «Нәрсә әйтте ул?»—диеп тинтерәп утыралар.

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә. Милләтебезне үстерү, яшьләрне милли һәм интернациональ рухта тәрбияләү өчен бары үзебез генә җаваплы. Бүгенге көндә хөкүмәтебез биргән мөмкинлекләрдән чыгып, районда яшь буынның телен, динен һәм киләчәген саклап калу өчен шартларны үзебез тудырырга тиешбез. Булган мөмкинлекләрдән файдалана белмибез икән, монда инде кемгә үпкәләргә?!

**М. МӨХӘММӘТГАЛИМ.**

Норлат шәһәре.

# Шәһәребез—туган йортыбыз

**Халык депутатларының шәһәр Советы башкарма комитетының 16 апрельдәге чираттагы утырышында шәһәрне төзекләндерү, территорияне, инженерлык корылмаларын санитария ягыннан тәртиптә тотуга кагылышлы мәсьәләләр каралды.**

**Утырышта халык депутатларының шәһәр Советының торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү буенча даими комиссиясенең барлык депутатларга һәм Норлат шәһәре халкына мөрәҗәгате хупланды.**

**Түбәндә мөрәҗәгатьнең тулы текстын урнаштырабыз.**

**ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ ШӘҺӘР СОВЕТЫ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ БУЕНЧА ДАИМИ КОМИССИЯСЕНЕҢ ШӘҺӘР СОВЕТЫНЫҢ БАРЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНА ҺӘМ ШӘҺӘР ХАЛКЫНА**

## МӨРӘҖӘГАТЕ

**Хөрмәтле депутатлар һәм Норлат шәһәре халкы!** Безнең барыбыз да шәһәребезне яратабыз. Ләкин ярату аңа карап соклану гына түгел, димәк, аны даими чиста, матур тоту, гүзәл итү, яшеллеккә күмү.

Әмма шәһәребезнең йөзе, аның санитария-техник торышы, күп кенә урамнары, тротуарлары, ишек аллары һәм балалар мәйданчыкларындагы җитешсезлекләр шәһәр кешеләрендә хаклы рәвештә канәгатьсезлек хисе уята.

Без эшчеләрне, хезмәткәрләрне, укучыларны һәм шәһәр җәмәгатьчелеген урамнарны, ишек алларын, микрорайоннарны, предприятие, учреждение, оешмаларга караган территорияләрне төзекләндерү һәм яшелләндерүдә актив катнашырга чакырабыз.

Без халык депутатларының шәһәр Советы депутатларын, территориаль депутат группаларын, йортлар һәм урам комитетларын чисталыкны сакларга, торак фондын, балалар мәйданчыкларын, юллар һәм тротуарларны үрнәк тәртиптә тотарга, яшел үсентеләрне саклап үстерергә, шәхси йортларны чиста, төзек хәлдә саклау эшен активлаштырырга чакырабыз.

Урамнар, ишек аллары матур һәм чиста булсын өчен һәр йорт һәм фатир хуҗасы, һәр хозяйка һәм пенсионер—барлык кешеләр шәхси җаваплылык тоярга тиеш.

Торак-эксплуатация һәм коммуналь хезмәтләр работниклары халыкны үзләре тора торган йортлар һәм алар тирәсен чиста тотарга чакырыгыз, аларны бу эшкә туплагыз!

Иптәшләр! Урамнарда, ишек алларында, производство һәм җәмәгать урыннарында санитария кагыйдәләрен бозучыларга аяусыз булыгыз! Янәшәгездә эшләүче иптәшләрегездән, фатир буенча, йорт буенча күршеләрегездән, яшьләрдән—барлык кешеләрдән һәр җирдә, һәрвакыт үрнәк тәртип, чисталык саклауны таләп итегез. Сез болар белән очраклы гына түгел, ә даими шөгыльләнергә тиешсез.

Бу барыбызның һәм һәркайсыбызның эше.

Шәһәребез—туган йортыбыз. Моны истән чыгармыйк!

Тәхлия Рәшитовна Абдуллина җитәкчелегендәге ферма эшчәннәре үрчем алу һәм дуңгызларны көр итеп үстерү өчен көчләрен кызганмыйлар. Биредә 15 кешедән торган тату коллектив эшли. Араларында Елизавета Мироновна Тихонова кебек өлкән яшьтәге, тәҗрибәле терлекчеләр дә, Гөлнур Гыйниятулловна Канәфиева кебек яшьләре дә бар. Ләкин аларның барысы да уңган, тырыш терлекчеләр. Елизавета Мироновна һәм Гөлнур Гыйниятулловна, мәсәлән, ана дуңгызлар группасында эшлиләр һәм матур гына нәтиҗәләргә ирешәләр.

Галина Николаевна Екамасова, Людмила Николаевна Алексеева да ферма алдынгылары. Аларның һәркайсы үз эш участокларында алыштыргысыз хезмәтчәннәр.

«Рассвет» совхозы дуңгыз караучылары Л. Алексеева, Г. Канәфиева, Е. Тихонова, Г. Екамасова иптәшләрне безнең фотохәбәрчебез Н. Азизов терлекчелек алдынгылары слетына килгәч фотога төшереп алган.

## СССР Министрлар кабинетында

1991 елның Май бәйрәме көннәрендә хезмәт ияләренә ял өчен уңай шартлар тудыру һәм эш вакытын рациональ файдалану максатыннан СССР Министрлар кабинеты 5 майдагы якшәмбе ялын җомга көнгә—3 майга һәм 12 майдагы якшәмбе ялын җомгага—10 майга күчерергә дигән карар чыгарды.

Бер үк вакытта предприятиеләргә һәм оешмаларга дефицит продукция эшләп чыгаруны арттыру максатыннан һәм башка кирәкле очракларда, профсоюз комитетлары белән килешеп, 4 майдагы ял көнендә эшләү хокукы бирелә. Бу көнне эшләгән өчен, үзара килешеп, бүтән көнне ял бирергә яки икеләтә күләмдә эш хакы түләргә. Кешенең теләге буенча бу көн еллык ялга кушыла ала, бу чагында ул көн өчен ял көннәренә түләгәндәге тәртиптә түләнә.

**Безгә язалар**

## Чүплектә күпме байлык?

Илдә азык-төлек һәм башка әйберләрнең бәяләре күтәрелгәч, чимал бәяләре дә күтәрелми калмагандыр. Шул исәптән кулланучылар кооперациясенең хәзерләүләр конторасы аркылы хәзерләнә торган азык-төлек һәм икенчел чимал да. Бу хакта район газеталарында әлегә бернинди хәбәр дә булмады.

Хәзерге ыгы-зыгы вакытта чимал да кирәктер. Аннан килгән акча беркемгә дә артык булмас иде.

Икенчел чималны хәзерләүнең түбән дәрәҗәдә булуын Норлат урамнары үтеп чыгып чокыр-чакырларны гына карасаң да моны күреп була. Тимер-томыр, чүпрәк, полиэтилен—күмпе телисең, шулхәтле. Әгәр дә икенчел чималны хәзерләүнең төрләре, чимал бәяләре даими хәбәр ителсә, чокырларда ятучы бу әйберләр халыкка кирәкмәсә дә, халык хуҗалыгына файдалы эшкә китәрләр иде.

Бу чималларны хәзерләү буенча әллә хәзерләүчеләргә план бирелмиме? Хәер, болардан хәзерләүчегә ни файда? Ул үзенә кирәген ит һәм тиредән дә ала. Бер түш иткә—дүрт тез сөяге дип, дүрт килограмм, я булмаса сигез килограмм скидка ясый, 40—80 сум аның кесәсенә керә дигән сүз.

Ә тирене ничек кабул итәләр? Төрле хәзерләүче төрлечә. Вөҗданы бөтенләй бетмәгәне күбрәк, ә вөҗдан дигән төшенчәне белмәгәне яртысын гына бирә. Тирене кабул итү тәртибе турында да газета битләрендә аңлатып язсагыз начар булмас иде.

Һәркемнең хәтерендәдер, чүпрәк-чапрак, сөяк җыеп урам буйлап йөрүче җыючылар була иде. Ә хәзер андый хәзерләүчеләр юкмы әллә? Булсалар кайда соң?

**А. УСМАНОВ.**

Норлат шәһәре.

# ЯПОНИЯ: саннар һәм фактлар

**СССР Президентының Япониягә визиты уңаеннан бу ил белән кызыксыну артты. Укучыларыбыз игътибарына кайбер мәгълүматлар тәкъдим итәбез:**

Япония архипелагында 6852 утрау бар. Халкы—123,6 миллион. Кешеләрнең уртача гомер озынлыгы: ирләрнеке—75,9, хатын-кызларныкы 81,8 яшь. Халыкның 80 проценты шәһәрләрдә яши. Ил башкаласы Токиода —12 миллион кеше.

**ЭКОНОМИКА**

Японияне҅ң эчке милли җитештерүе АКШ доллары белән 2867 триллион тәшкил итә. Еллык үсеш темплары—4,5 процент. Җан башына керем —23365 доллар.

**ЭШ БЕЛӘН**

Эшләүче японнарның 24,2 проценты җитештерүдә, 7,6 проценты авыл хуҗалыгында, 22,8 проценты сәүдәдә, 30,9 проценты хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә, 9,4 проценты төзелештә эшли. Эшсезлек дәрәҗәсе 2,1 процент.

**ПРОМЫШЛЕННОСТЬ**

1990 елда 13486796 автомобиль, 99 миллион тонна корыч, 2,99 миллион персональ компьютер, 5,8 миллион данә вордпроцессор җитештерелгән.

**ПРОФСОЮЗЛАР**

Япониядә дөнья эшчеләре хәрәкәте тарихында профсоюзда әгъза булып торучылар саны иң азы—25,9 процент. 15 ел дәвамында зур забастовкалар булганы юк. Япониядә 1851673 корпорация, компания һәм фирмалар бар.

**ЭШ ХАКЫ**

Япониядә уртача айлык эш хакы 350 мең иена. (2,5 мең АКШ доллары).

**ҖӘМГЫЯТЬ**

Япония парламентына—100 ел. Төп парламент партияләре 6. Парламентта депутатлар саны—762. Илдә 200 меңгә якын дини оешма бар.

Император гаиләсе һәм тәхет ягыннан кардәшләр 23 кеше, япон ел хисаплау тәртибе буенча хәзер (Япониядә Хэйсэй дәверенең өченче елы бара). Императорның эш хакы 257 миллион иена (елга). Парламент депутатларының эш хакы елга 18274250 иена.

Илдә 67 төрмә бар. Аларда 44247 кеше тотыла.

Белем алу бәясе (туганнан алып вуз тәмамлаганчыга кадәр бер балага) 24 миллион иенадан күбрәк. Хосусый уку йортларында —32 миллион иена, медицина вузларында—60 миллион иенага якын.

**ОБОРОНА ЧЫГЫМНАРЫ**

Ил бюджетында аның өлеше—6,28 процент. Япония армиясендә 255 мең кеше. Генштаб аппараты 163 кешедән тора.

**ТӨП ЭКОНОМИК ЗОНАЛАР**

Канто зонасының милли җитештерүдәге өлеше 40 процент. Кансайныкы (Осака мегаполисы)— 30 процент.

# Игенчеләр шулай уйлый

Җилле, сүрән көн бер дә кулай түгел шул игенче өчен. Әнә алдагы кояшлы көннәрдә өлгергән участокларда тунга сөрелгән җирләрдә тырмалау үткәрделәр. 120 гектарда чәчү алдыннан ашлама тараттылар. Инде шуңа ялгап чынлап торып тырмалау эшенә керешергә иде дә бит—яңгыр кирәк! Җир туң, ашыгып кына әлләни ота торган ел түгел дип исәплиләр «Заря» колхозында. Әлегә борчак чәчеләсе җир әзерләнә, чәчкечләр көелгән, агрегатлау бара, икенче башта кырлар тәртипкә салына. Менә-менә уҗым басуларын тукландырырга керешергә ниятлиләр игенчеләр. Ашыгырга ярамый, әмма һич кенә дә сузарга, акрынларга да ярамый! Быел Заря» колхозын тарихында булмаганча зур эш күләме көтә. Узган явымлы ел иң элек алар кебек сазлык, иңкүлекле кырлары булган хуҗалыкларның канына төште. Күздән «Заря» да 600 гектардан артык тунга сөрелмәгән җир, 50 гектар җыелмаган карабодай, 10 гектар күпьеллык үлән, 30 гектар кукуруз һәм бераз шикәр чөгендере калды.

Болар һәммәсе язгы кыр эшләрен дә тоткарлаячак, уңышка да йогынты ясаячак, әлбәттә. Әмма ни генә булмасын, бу эшләрне башкарырга, язгы чәчүне уңышлы үтәп чыгарга кирәк—колхоз белгечләре бүген бөтен көчне, бөтен игътибарны шуңа юнәлтергә тырышалар. 13 апрельдә чәчү алды җыенында бу хакта механизаторлар белән дә уртага салып сөйләшү булды, ярыш шартлары, түләү тәртибе җиткерелде. Соңгысына быел зарялылар бераз үзгәреш кертергә ниятләделәр. Техниканы үзвакытында сыйфатлы итеп әзерләүче һәр механизаторга хезмәт хакын 20 процент артыграк түләргә ясадылар. Чәчү өстендә көнлек эшләп чыгару нормаларын 25 процентка киметеп, хезмәткә түләүне 30 процентка арттыру турында «Рассвет» совхозы инициативасын да үзләрендә кулланырга булдылар. Бүген колхоз җитәкчелеге кул астында чәчү чорына эш планы, расчетлар да бар, һәр механизаторга техника төгәл беркетелгән, шул ук вакытта иң җаваплы участокларга коммунистларны куярга да онытмаганнар. Техника, кадрлар мәсьәләсе уңай хәл ителгән. Быел эш нигездә ике сменада оештырырга планлаштырыла. Ярдәмгә шефлар—73 нче хәрбиләштерелгән янгын часте өч механизатор, ә «Агропроммехмонтаж» ПМКсы ЗИЛ автомашинасы бирергә булды. Чәчүчеләр—профтехучилище курсантлары, төзүчеләр. Ә кадрларның нигезен тәҗрибәле, белемле механизаторлар тәшкил итә. Баш агроном В. В. ПИТУБАЕВ аларны бәйнә-бәйнә санап китә. Әнә туңга сөрү җирләрен тырмалауга иң беренче булып Аркадий Акмурзинны тешерделәр. Тәҗрибәсе өстенә кулы да җиңел аның. Бертуган Владимир һәм Юрий Казаковларга да теләсә нинди эшне куркмыйча тапшырырга була. Шикәр чөгендере игү белән Иван Матвеев һәм Валерий Казаков шөгыльләнәчәкләр. Яшьләр—Василий Сенькин, Николай Николаев, Александр Марфинга да зур өмет баглана. Мондый егетләр белән эш барырга тиеш! Әлбәттә, оештыру, туклану мәсьәләләрен дә күздән ычкындырырга ярамый. Соңгысын 4 тапкыр оештырырга уйлыйлар. Бу чорга җитәрлек азык-төлек тупланган. Орлыкның сыйфаты да елына күрә ярыйсы. Якын арада шикәр чөгендере орлыгын да туплап бетерәчәкләр. Димәк, эшләргә генә кала.

—Игенчеләрнең быелгы ел кыенлыкларын аңлап, һәр сәгатьне, минутны эшкә җигәселәренә исәп тотабыз,—ди колхоз рәисе Ф. Х. Хөсәенов.—Әлегә кәефләре әйбәт, омтылышлары зур. Шундый настрой булганда...

Бусын анык кына әйтеп бетерергә читсенә әле рәис. Әмма расчетларда ул ачык күренә: шундый кәеф, техник тәэмин ителеш белән кыр эшләрен 16—18 көндә төгәлләргә уйлыйлар зарялылар. Шулай була күрсен!

**С. ХӘЙРУЛЛИНА.**
«Заря» колхозы.

**«Кондырча» колхозы механизаторлары Хафиз Халитов һәм Вәгыйзь Ибәтуллин—байтак язны кырда каршылаган кешеләр. Игенче хезмәтенең тынгысызлыгы, шул ук вакытта аның иң гуманлы, иң тыныч һөнәр булуы аларда үз хезмәтләре белән чиксез горурлык уятырга өлгерде инде. Механизаторлар өчен тагы тынгысыз көннәр җитте. Хафиз Халитов М. Бакировның, Вәгыйзь Ибәтуллин С. Гомәровның аренда звенолары составында язгы эшләрне башлап җибәрделәр. Хәзер күпьеллык үләннәр тукландыру, уҗым чәчүлекләрен тырмалау кебек эшләр белән мәшгульләр алар.**

**Н. Азизов фотосы.**

# Алмаш та кирәк

Быел район басуларына язгы чәчүгә мең ярымга якын механизатор чыкты, аларга промышленность предприятиеләреннән ярдәмгә 103 механизатор, авыл интеллигенциясе составыннан байтак кына чәчүчеләр килде. Һәрберебезгә мәгълүм: ел бик эшле, чәчү өсте киеренке булырга тиеш, шуңа да чәчүдә эшләячәк механизаторлар саны да быел алдагы еллар белән чагыштырганда артыграк таләп ителде. Бу, әлбәттә, хуҗалык җитәкчелеге алдында байтак кына кыенлыклар тудырды. Авылларда җыеннар үткәреп, хәлгә аек бәя бирергә, ярдәм итәргә көченнән килгән пенсионерларны, интеллигенция вәкилләрен эшкә тартырга тырыштык. Әмма, бәхеткә, механизатор кадрлар әзерләү белән даими шөгыльләнгән, 99 нчы СПТУга һәр елны үз стипендиатларын җибәреп торган хуҗалыклар мондый авырлыкны кичермәделәр. Әйтик, «Татарстан», Мичурин исемендәге колхозлар, «Рассвет» совхозы, «Большевик» колхозы быел ике сменалы эш өчен кадрларны бердә читтән алмадылар. Сүз уңаеннан, алар якын елларда да кадрларга тилмермәячәкләр, чөнки шул ук «Большевик» колхозының 99 нчы СПТУда 15 укучысы бар. Алда телгә алынганнардан тыш Хафизов исемендәге, Мичурин исемендәге, «Москва», «Таң» колхозлары да кадрлар әзерләүгә җитди карыйлар, елның-елында училищега укучылар җибәрәләр. Әмма бу нәрсәгә һәр җирдә дә әһәмият бирелми әле. Алар—иң элек бүген язгы чәчүгә кадрлар туплауда кыенлык кичергән хуҗалыкларда. Мәсәлән, «Сәлчә» совхозы, Үз территориясендә ике дистәдән артык вак предприятие-оешмалары булып та алар нишләптер быел да уртак тел табып, чәчүгә кадрлар комплектлаштыра алмадылар. Шул ук вакытта аларда киләчәктә мондый проблема булмас диеп әйтә торган да түгел, чөнки 99 нчы СПТУда сәлчәлеләр шулай ук юк. Быел без аларга 13 механизатор, 8 трактор юлладык, өстәвенә, училищедан 8 курсант та җибәрдек. Әмма бу эш түгел! Кисәтеп куябыз: киләчәктә «Алга», «Комбайн»,Знамя Октября», «Правда» колхозларын һәм «Мамык» совхозын да шундый ук хәл көтә. Чөнки бүген андагы механизаторларның күбесе өлкән яшьтәгеләр, ә аларга алмаш әзерләү, кадрлар укытуга караш бик сүлпән.

Авыл проблемасы, сүз дә юк, бүген уртак мәшәкатькә әйләнде. Чәчүгә керешүдән күп элгәре аны оптималь срокларда, уңышлы итеп үткәрү өчен бөтен резервлар барланды, Быелгы язда кыр эшләре күләменең артуын истә тотып, район промышленность предприятиеләре, оешмаларына ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать иттек. Шефлар моның әһәмиятен аңлап, техника, механизатор кадрлар белән булыштылар. 127 нче ПМК «Тәрнәс» совхозына 4 трактор җибәрде. Норлат технологик транспорт идарәсе, шикәр заводы, хуҗалыкара төзелеш оешмасы да шундый ук ярдәмне авырсынмыйча күрсәттеләр. Бу җәһәттән райондагы авыл профтехучилищесының булуы да зур терәк әле. Быел училище 10 техника берәмлеген һәм 146 укучысын кыр эшләре кампаниясенә юллады, өлкән курс укучылары үзлектән тракторчылар, ә калганнары чәчүчеләр булып эшләячәкләр. Шулай һәрьяклы тырышлык белән бүген хуҗалыкларда механизатор кадрлар тулысынча тупланган, агрегатлар кырда инде. Аларның күбесен тәҗрибәле, инде икмәк өчен көрәштә ныгыган механизаторлар тәшкил итә. Аларга ышанырга да, таянырга да була, язгы яуда да алар сынатмаслар. Әмма бер нәрсәне онытмыйк! аларга алмаш кирәк һәм аларны даими рәвештә әзерләп торганда гына авыл яшәр, табыннарыбыз күркә булган икмәк үсәр.

**М. ШӘҺИДУЛЛИН,**
авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең кадрлар буенча экономисты.

# УҢЫШКА ТЫРЫШЛАР ИРЕШӘ

Без фермаларыбыз механикалаштырылган, эш шартлары җайлы дип бер дә мактана алмыйбыз. Бу көннәр алда әле. Карлар эри башлаганнан бирле юлсызлыктан интегәбез. Мин һич тә авылыбыз Урта Камышлы турында әйтмим. Биредә киресенчә тирә-як авыллардагыга караганда да чисталык, җыйнаклык хөкем сөрә. Менә фермалар тирәсендә дә шундый тәртип булса иде. Бер фермадан икенчесенә пычракка чуммыйча чыгу мөмкин түгел. Бу күренеш җәй урталарына кадәр дәвам итә. Ярый әле җәяүлеләргә, менә азык ташучы терлекчеләр бу хәлдән зур җәфа күрәләр. Ә алар бездә инде күбесенчә хатын-кызлар. Мәсәлән, Анна Семенова дүрт ел инде шул урында. Дуня Кузьмина, Валентина Левакова һәм башкалар (алар барысы уң хатын-кыз) азыгын да үзләре ташып яшь таналар карыйлар. Биредә әле бар җирдә дә кул хезмәте куела. Сүз дә юк, азык төяп, үзең ташу, бушату хатын-кыз эше түгел. Әмма алар күнгән инде: авыр дип тормыйлар, һәрвакыт алгы сафта булалар.

Сөтчелек фермасында да әле барысы да искечә. Шуңа карамастан, бүгенге көндә колхозда һәр сыер уртача 12 шәр килограмм сөт бирә. Иң алда баручы савымчылар—Людмила Михеева, Мария Бочкарева һәм башкалар. Хәер, мактау сүзләре әйтә калсаң, беркемне дә атамыйча калдырасы килми. Әйтәсе сүземнең төп мәгънәсе дә шул: яхшы, тырыш кешеләргә җиребез бай әле. Терлекчеләр ярдәмләшеп, бердәм эшлиләр. Коллективта ныклы дисциплина хөкем сөрә.

Ә дисциплина хезмәт коллективында төп фактор, минемчә. Сөт саву буенча соңгы вакыттагы уңышларыбызны нәкъ шулар аңлата да. Беренче кварталда һәр сыердан уртача 1024 килограмм сөт савып алынды.

Киләчәктә эш шартлары яхшыртылгач күрсәткечләр дә артыр иде. Менә быел фермалар арасында юл салырга уйлыйбыз, азык цехына яңа җайланмалар урнаштырабыз.

**Ә бит терлекче күңелен биреп эшләсен өчен иң беренче чиратта эш шартлары тудыру зарур.**

**Ю. ВАРМАНДЕЕВ,**
Мичурин исемендәге колхозның сөтчелек фермасы мөдире.

# Коллектив яңарыш кичерә

Киекле авылы ашханәсе олы юл өстенә урнашкан. Шуңа күрә монда тамак ялгарга керүчеләр арасында чит төбәк кешеләрен күп очратасың. Ерак юлдан арып-талып килүче шоферлар һәм юлаучы пассажирлар бу ашханәгә бик теләп керәләр. Чөнки, бердән, монда ризыкны тәмле әзерлиләр, ассортимент төрле, икенчедән, ашханә залы кунак көткән өй кебек ямьле, пөхтә итеп җыештырылган, эшләүчеләр игътибарлы, йомшак мөгамәләдә. Юлаучыга тагын ни кирәк?

Авылның үз кешеләре дә ашханә юлын аз таптамыйлар. Кайнар ашларны өеңдә әзерләсәң дә төрле камыр ризыкларын, кондитер әйберләрен моннан сатып алу уңайрак. Чөнки ашханә кызлары хәзерләгән пирог, чәкчәк, бавырсаклар, печенье, кош телләре өйдә пешкән кебек тәмле була. Хәзерге заманда оның, маен, бүтән кирәген эзләп көн уздырганчы, әзерне аласың да кайтасың. Оста куллы Рәтифә апа Насретдинова пешергән пироглар мичтән чыккан көенә синең өстәлеңә кайтып утыра ләбаса. Буфетта сирәк-мирәк конфет, прәннек ише татлы ризыклар да була. Люция Гомәрова пешергән кондитер әйберләре фабрикадан кайтканнарыннан тәмлерәк тә әле. Монда авылның олысын-кечесен куандырып мороженое да саткалыйлар. Берничә төрле җимеш суы һәрвакыт сатуда тора. Көненә 200—250 сумлык камыр ризыклары пешереп сатыла. Авыл халкы монда туйларга савым да хәзерләтә.

Ашханәдә бер көнгә уртача 180—200 кешегә хезмәт күрсәтәләр. Ә аерым көннәрдә бу сан 300гә дә җитә. Барлык бу эшләрне

Тәмле ашлар остасы Р. Насретдинова.

13 кешедән торган коллектив башкара. Эшләүчеләрнең күбесе яшьләр, әмма хезмәтләре буенча махсус әзерлек алган кызлар. Ашханәнең мөдире Миләүшә Гарифуллина үзе дә Казан кооператив техникумының көндезге бүлеген тәмамлаган яшь кадр.

Моннан ел ярым, ике еллар элек кенә әле бу ашханә район җәмәгать туклануы предприятиеләре арасында койрыкта сөйрәлүче иде. Коллективта да таркаулык, үзара бер-береңне яратмау хөкем сөрә иде. Соңгы вакытта коллектив яңартылды, анда дустанә мөнәсәбәт урнашты. Шуның нәтиҗәсе буларак хезмәт күрсәткечләре дә яхшырды, кызлар планнарын үти башладылар. Узган ел ашханәнең эчке бизәлешен яңарттылар, өлешчә ремонт ясалды.

...Киекле авылы ашханәсе олы юл өстендә урнашкан. Хәзерге вакытта коллективның рухи һәм матди яңару чоры. Хәерле сәгатьләр булсын!




Киекле ашханәсе реконструкциядән соң.

**Фома авылында яшәүче әниебез Зәйтүнә Габбас кызы Гыйрфановага 50 яшь. Без аны юбилее белән кайнар котлыйбыз, корычтай нык сәламәтлек, озын гомер, диңгез киңлегедәй шатлык телибез.**

**КЫЗЛАРЫ, КИЯҮЛӘРЕ, УЛЛАРЫ.**

# Күңелле яшибез

Андреевка авылында төрле культура-масса чаралары еш үткәрелә. Соңгы көннәрдә генә дә шуларның икесе турында берничә сүз әйтеп үтәсе килә. Беренче апрель көненә аталап «Көлке көне» үткәрдек. Шактый кызыклы программа әзерләнгән иде. Төрле шаян җырлар, биюләр башкарылды. Тамашачыларга аеруча Геннадий Дегтярев чыгышы охшады. Ул «Гүзәл кыз» булып шаян җырлар башкарганда залда көлке тавышы тынмады.

Әле күптән түгел генә «Уйнагыз, гармуннар!» бәйрәмен үткәрдек. Авылда барлыгы 20 дән артык гармунчы исәпләнә. Бу көнне шуларның унбере культура йортына җыелганнар иде.

Василий Дмитриевич Абрамов гаҗәеп уен коралы —гармунның килеп чыгышы, безнең якларга килеп чыгу тарихы белән таныштырды. Аннан соң һәркем үзенең номеры белән чыгыш ясады. Хезмәт ветераны, пенсионер, элеккеге авыл Советы рәисе Кирилл Андреевич Абрамовның оста уйнавы тамашачылар күңеленә аеруча охшады. Шулай ук пенсионер, күп еллар буе «Восход» колхозында экономист булып эшләүче Алексей Михайлович Максимовның уены да тамашачыларның күңеленә хуш килде.

Биредә гаилә ансамбльләре дә бар иде. Виталий Петрович Егоров үзенең уллары Евгений һәм Андрей белән чыгыш ясады. Андреевкалылар аларны зур алкышлар белән озаттылар. Анатолий Петрович Леваков, Леонтий Дмитриевич Абрамов, Геннадий Кузьмич Дегтяров, Анатолий Максимович Данилов, Василий Дмитриевич Абрамовның чыгышлары да зур кызыксыну белән тыңланды. Соңыннан чыгыш ясаучыларга грамоталар тапшырылды. Иң оста уйнаучылар призлар белән бүләкләнделәр.

Авыл халкы өчен гармун белән очрашу бәйрәме, язгы чәчү алдыннан ял хезмәтен үтәде дияргә мөмкин. Аны үткәрүдә культура йортының художество җитәкчесе Василий Дмитриевич Абрамов зур тырышлык күрсәтте. Ул бу һөнәре белән бергә, мәктәптә җыр дәресләрен дә алып бара. Көзге урып-җыюда комбайн штурвалы артына утыра. Ул гына түгел, сайлау кампанияләре чорында күп тапкырлар участок комиссиясе рәисе итеп сайланды.

Менә шундый тырыш, мавыгучан кешеләр булганда авыл халкына да яшәргә күңеллерәк.

**В. КОЛЕСНИКОВА,**
Авыл Советы рәисе.

# Газны дөрес һәм файдалы куллануны пропагандалау айлыгы бара

**Җир асты газүткәргечләренә зыян китермәү һәм аварияләр булдырмау максатында «Лениногорскгаз» идарәсе белән язма рәвештә килешү төземичә җир казу эшләре алып бармагыз.**

**Җир казу машиналары машинистлары, эшчеләр, прораблар һәм мастерлардан язмача рөхсәт, ягъни җир казу эшләре алып бару турында белдерү таләп итегез.**

**Гамәлдәге газүткәргечләре якында булса, казу эшләре газ хуҗалыгы вәкиленнән башка үткәрелергә тиеш түгел.**

**Гамәлдәге газүткәргеч янында җир казу эшләре үткәрсәгез сак булыгыз! Биредә эшне экскаватор да, бульдозер да түгел, бары тик кул белән генә алып барырга кирәк.**

**Идарә вәкиленнән башка газүткәргеч үтә торган җирдә казу, шулай ук газүткәргеч ачылган урыннарны күмү тыела.**

**Әгәр казыганда газүткәргеч зарарланса, бу урында эшне туктатырга, кешеләрне траншеядән чыгарырга. Куркыныч турында авария-диспетчерлык хезмәтенә хәбәр итегез. Телефон: 2—28—58.**

**Газүткәргечнең зарарлануы дәүләткә зур зыян китерә, шулай ук бәхетсезлек очрагы китереп чыгару да мөмкин. Газүткәргечкә зарар китерүдә гаепләнүче җаваплылыкка тартылачак.**

**Газүткәргеч трассасында вакытлы корылмалар төзү, төзелеш материаллары, утын һәм башкаларны өю тыела.**

**Газүткәргечнең изоляциясен саклау максатларында газүткәргеч ачылган урыннарны бары тик төеп тыгызланган комлы туфрак белән генә томаларга кирәк.**

**«Лениногорскгаз» идарәсенең Норлат газ службасы.**

**«Рассвет» совхозы коллективы**
**ГАЯЗ СОЛТАН улы ӘХМӘТВӘЛИЕВның**
**вакытсыз үлүе сәбәпле аның туганнарының һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.**

**Киекле авыл Советы коллективы авыл Советы депутаты**
**ӘХӘТ ӘСХӘТ улы МӨХЕТДИНОВның**
**фаҗигале төстә үлүен белдерә һәм Әсхәт Нургата улы Мөхетдиновның, мәрхүмнең туганнарының һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.**

**Район электр челтәре бүлү коллективы мастер**
**МАНСУР НУРИҖАН улы НУРУЛЛИНның**
**вакытсыз үлүен хәбәр итә һәм мәрхүмнең туганнарының, якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.**

**БЕЛДЕРҮЛӘР**

**Октябрь районы башкарма комитетының тармакара производство предприятиесенә даими эшкә кочегар, шәһәр мунчасының чишенү бүлмәсенә дежурный, реагент хуҗалыгына оператор, слесарь, су үткәргечнең чистарту корылмаларында ГАЗ-53 автомашинасын йөртүче кирәк. Түләү штат рапсисаниесе буенча.**

x x x

**Норлат район электр бүлү челтәренә (подстанция) КК-12,5 кранына крапчы һәм ЗИЛ-131 (телевышка) автомашинасын йөртүче кирәк.**

**Подстанция конторасына мөрәҗәгать итәргә.**

**Телефон: 2—14—55.**

**МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.**


Учредительләр— халык депутатларының Октябрь район Советы һәм КПССның район партия оешмасы.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Нурзия ФӘСХЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор— ЗӨЛФИЯ ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 46. Тираж 3.350.